Бүгенге санда:

Лидер булу җиңелме? 2 бит


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе 26 август 2015 ел

№ 62 (10591)


**27 августка һава торышы:** болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көньяк-көнбатыштан, 2-4 м/с; температура көндез +23°C, төнлә +14°C

# Мөгаллимнәр олы киңәшмәгә җыела




ШӘҺӘРНЕҢ 2НЧЕ УРТА МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ МАРИНА ГАЛКИНА, "РОССИЯНЕҢ ПЕДАГОГ-ПСИХОЛОГЫ – 2015" КОНКУРСЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА ЭТАБЫ ЛАУРЕАТЫ ЕЛЕНА ИСАЕВА ҺӘМ БАЛАЛАРНЫ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ БУЕНЧА ИҢ ЯХШЫ ТӘРБИЯЧЕ РӘСЛИМӘ МОСТАФИНА

**Нурлат районының мәгариф идарәсе республиканың гомуми күрсәткечләр рейтингында 36нчы урыннан 26нчыга күтәрелгән, тәрбия процессы буенча алар 7нче урында.**

Иртәгә, 27 августта Мәдәният сараенда педагогларның август киңәшмәсе узачак. Быелгы олы киңәшмә "Заманча мәгариф: яңа стратегик ориентирлар, яңа карарлар" дигән темага багышлана. Киңәшмәдә мәктәпләрнең эшчәнлеге, укытучының роле, тәрбия хакында уртага салып сөйләшенәчәк. Пленар утырышта узган уку елына йомгак ясалачак, проблемалар каралачак һәм бурычлар билгеләнәчәк. Районда үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм белем бирү белән 1208 педагог шөгыльләнә, шуларның 749ы – гомуми урта белем бирү системасында, 338е -мәктәпкәчә, калганнары өстәмә белем бирүдә.

Район педагоглары алга таба да белем сыйфатын күтәрү мәсьәләсенә аерата игътибар биреп эшләргә планлаштыра. Быелгы БДИны шәһәр мәктәпләре укучылары яхшырак тапшырган. Лидерлар шәһәрнең 4нче мәктәбе (директоры Солтан Әхмәтҗанов), икенче позициядә гимназия (Владимир Кашкаров), өченчедә шәһәрнең 2нче урта мәктәбе (Елена Матавина) һәм Урта Камышлы мәктәбе (Марина Герасимова). Районның 8 төп мәктәбе арасында Бикүле мәктәбе (Нурдидә Вәлиева) лидер. Олы киңәшмәдә район башлыгы грантларын тапшыру, яшь белгечләрне тәбрикләү, яңа уку елына әзерлек буенча смотр-конкурста катнашкан мәгариф учреждениеләрен билгеләп үтү һәм тармак бүләкләрен тапшыру да планлаштырыла.

Киңәшмә эшендә район башлыгы Равил Кузюров, ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Гөлнара Габдрахманованың катнашуы көтелә. Секция утырышлары исә 21-29 августта шәһәр мәктәпләре базасында уза.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### ФИНИШКА ЧЫКТЫЛАР

Район хуҗалыкларында урып-җыю эшләре азагына якынлашып килә. Кичәге көнгә барлык мәйданнарның 85 процентыннан 68562 тонна иген җыеп алынган, бер гектарга уртача уңыш 20,2 центнер тәшкил итә. Басуларда берүк вакытта көзге чәчү һәм сөрү эшләре дәвам итә – район игенчеләре барлык мәйданнарның 47 процентында уҗым чәчкәннәр, 18 мең гектардан артыграк туфрак эшкәртелгән.

### ТАТЛЫ ТАМЫРГА ЧИРАТ

Нурлат шикәр заводында 27 августтан татлы тамыр кабул итәргә, ә 30ыннан эшкәртүгә керешергә планлаштыралар. Бу көннәрдә исә биредә яңа сезонга әзерлек эшләрен тәгәлләп киләләр һәм эшче кадрлар туплау белән мәшгульләр. Район хуҗалыклары да шикәр чөгендере казуга әзерлек сызыгында торалар.

### ЯРМИНКӘЛӘРГӘ КИЛЕГЕЗ!

**27 августта** шәһәрнең үзәк мәйданында район мөгаллимнәренең август киңәшмәсе кысаларында мәктәп ярминкәсе булачак. Бу көнне нурлатлылар яшелчә, җиләк-җимеш, кайнатма, тозланмалар һәм кул эшләнмәләре дә сатып ала алалар.

**29 августта** исә Республика көне уңаеннан иртәнге 7дән көндезге 12гә кадәр авыл хуҗалыгы ярминкәсе һәм бәйрәм концерты булачак.

### БАРЫГЫЗ ДА ГОМУМШӘҺӘР ӨМӘСЕНӘ!

Алда торга Республика көне уңаеннан һәм "Яшел Россия" Бөтенроссия экологик өмәсен үткәрү кысаларында, 28 августта Нурлатта гомумшәһәр өмәсе игълан ителә.

СОРАШТЫРУ

# Районыбыз белән горурланабыз

**Бу көннәрдә Октябрь районы оешуга 85 ел тула.**

Юбилей датасы уңаеннан без нурлатлылардан кече Ватаныбыз тарихында яңа сәхифә ачкан вакыйгалар турында ниләр белүләрен сораштык.

**Флюра Морзаханова, Кама арьягы һәм Нурлат шәһәре тарихы тәбәк музее директоры:**

– 1930 елның 10 августында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Татарстан АССРның гамәлдә булган административ бүленешен кыскарту турында карар кабул итте һәм 46 район, шул исәптән үзәге Норлат булган Октябрь районын да оештыруны раслады. Моны ВЦИК Президиумы Карарыннан архив язуы да раслый, ул безнең музей фондында саклана һәм зур тарихи хәзинә булып тора. Бүген документлар һәм экспонатлар ярдәмендә без районның оешкан көннән алып бүгенге көнгәчә тарихын барлый алабыз. Болар барысы да музей экспозицияләрендә бар, һәм аларны нурлатлылар гына түгел, район кунаклары да карый ала.

**Галина Макеева, туган як тарихын өйрәнүче, район газетасының җәмәгать корреспонденты:**

– Мине районыбызның чордашы дисәк тә була, бер ел гына алдан туганмын. Заманында Чулпанда берничә тапкыр булган Столыпин ук безнең җирлекләргә зур киләчәк һәм икътисади үсеш юраган, район территорияләрендәге җир участокларын сатуга да ризалык бирмәгән. Чөнки шул чакта ук тимер юл төзелеше кételгән, урман эшкәртү сәнәгате көйләнә башлаган. Район оешкан вакытка Нурлатта урта мәктәп, элеватор эшләгән, аннан республикада беренче МТС ачылган. Нәкъ әнә шулар районның алдагы үсешенә этәргеч биргән дә инде. Һәм барлык шул еллар эчендә районның алыштыргысыз юлдашы "Дуслык" газетасы булды, ул Октябрь районы оешуның икенче елында чыгарыла башлады.

**Зоя Апышкова, педагогик хезмәт ветераны:**

– Районыбыз белән горурланам. Мин – Октябрь районының Нурлат районына үзгәртелүенең турыдан-туры шаһиты. Шәһәрдә 1964 елдан бирле яшим, биргә укудан соң, юллама буенча килдем һәм 40 ел буе 1нче мәктәптә эшләдем. Мин Октябрь районы составына Аксубай кергән чорга да эләктем әле. Әнием "Союзпечать"нең Аксубайдагы филиалы начальнигы булып эшли иде һәм хисаплар белән Нурлатка еш йөрде. Торак пунктларның административ үзәктән еракта булуы Октябрь районын аеруга китергәндер дә, бәлкем. Һәм бу карарны дөрес дип саныйм. Чөнки район үзенең яшәү дәверендә мөстәкыйльлеген раслап, республика районнары арасында лаеклы урынын алуга ирешә.

**Маргарита ЛИТТА сораштЫ**

ЯШӘЕШ

# Бәрәкәтле гомер

**Колбай Мораса авылында гомер итүче мәртәбәле педагог, ихтирамга лаек хатын-кыз, Габдулла Кариев музее тормышына икенче тапкыр җан өргән Роза Сахипзадә кызы Борһанованың гомер бәйрәме. Җиде унлыкны берәгәйләп җыйган дисбе бик күп вакыйгаларны үз эченә алган.**

Көрнәле Әмзә авылында Сахипзадә абый белән Рабига апа корган ояның иң тәүге кошчыгы, иң татлы җимеше булган ул. Аттестатны кулына алгач, башлангыч мәктәптә эшкә калган - беренче хезмәт "чирканычы" алган, балалар күңеленә юл салырга өйрәнгән. Шул чак аның йөрәгенә Колбай Морасада рус теле һәм әдәбияты укыткан Наил Борһанов мәхәббәт күпере салып, мәңгелек тормыш иптәше иткән. Ирен Бөек Ватан сугышында югалткан Закирә апа олы улы Наилнең башлы-күзле булуына бер шатланса, яшь-яшь, җиләк кебек Розаның уңганлыгына, булдыклылыгына мең куана. Читтәге балалары кунакка кайтканда йөзләре ачык, телләре тәмле, мунчалары яккан, аш-су өстәлдә әзер тора. Бер-бер артлы Фәрит белән Чулпан туа. Эштә дә бергә эшли, йорт мәшәкатьләрен дә бергә күтәрәләр Борһановлар.

Роза апа читтән торып Казан Дәүләт университетының география факультетын тәмамлый. Кырык елдан арткан укытучылык хезмәтендә бер генә классның җитәкчесе булып кала ул. Шушы бердәнбер чыгарылыш классы - 1971нче елны урта мәктәпне тәмамлаучылар – әле дә Роза апа белән бик тыгыз бәйләнештә. 2011нче елда аларның мәктәп белән хушлашуларына 40 ел тулды. Габдулла Кариев музеенда бик матур очрашу узды. Укучыларының ялкынланып сөйләүләренә карап, алдыбызда 60тагы абый-апаларның гөрләп торган яшьлеге, укытучы апабызның дөрләп янган йөрәге күз алдына килде.

Ул чакта дипломлы белгечнең балалар белән оста эшләвен исәпкә алып, Колбай Мораса мәктәбендә директорның сыйныфтан тыш эшләрне оештыручы урынбасары итеп билгелиләр һәм ялгышмыйлар. Янып яшәмәсә, республиканы "дер" селкетеп, Колбай Мораса мәктәбенең 400 еллык юбилеен уздырыр идемени соң Роза Сахипзадә кызы? Галим Әнвәр Хәйри дәлилләренә таянып, 1995нче елның маенда олы бер Сабантуй үтте мәктәптә. Ул укытучыларның иң зур җыенына, мөгаллим хезмәтенә мәдхиягә әйләнде.

1994нче елда мәчеткә манара куелды, дини укулар башланып, балалар ислам нигезләре өйрәнде. Динебезнең бишеге булган Болгарга барып, җыенда мөнәҗәтләр әйтеп, призлы урыннар яулыйлар. Бу эшләрнең чишмә башында Роза апаның тынгысызлыгы, үҗәтлеге, максатка ирешү юлында киртәләр үтә белүе ята иде. Ул елларда мәктәп чын мәгънәсендә икенче өй булды. Көннең беренче яртысында дәресләр укыган балалар сәгать дүрттә тагын мәктәпкә агыла. Кем җыелыш уздыра, кем стенгазета чыгара, кем концертка әзерләнә... Көзләрен ындыр табагында эшләү, чөгендер алу, аны төяп озату – мәктәпнең производство бригадасы хезмәте шул. Шушы тармакның җитәкчесе буларак, Роза Сахипзадә кызы оештыру эшләре өчен генә түгел, балалар иминлеге өчен дә тулы җаваплылыкта булды.

Роза апа гел елмаеп - көләп, балкып килеп керә иде класска. Географияне бик яратып укытты. 1978нче елда укытучы Хәлимә апа Усманова белән икәүләп 30 баланы җыеп, Белоруссиягә алып чыгып киттеләр. Мәскәү – Могилев - Минск шәһәрләре һаман истә... Барлык казанышларын искә алып, Роза Борһанова "Халык мәгариф отличнигы" күкрәк билгесе белән бүләкләнә, хезмәт ветераны исемен ала. Исеме 2013нче елда дөнья күргән "Нурлат җиренең күренекле кешеләре" китабына кертелә.

Мәктәптән лаеклы ялга чыккач та, җиде ел Габдулла Кариев музеен җитәкли Роза Борһанова. Музейның яңадан тууы–реконструкцияләү нәкъ аның җитәкчелегендә барды, аны иң мәртәбәле кунакларның кабул итәрлек дәрәҗәгә җиткереп калдыручы – Роза апабыз. Бүген тарих йортының һәр почмагы аның күңел җылысын, аңа гына хас тәртипне, пөхтәлекне саклый. Без, аның дәвамчылары, шулай ул салып калдырган традицияләргә тугры булып, аны баетып эшләвебез белән бәхетле.

Роза апаның күңел киңлеге һәркемгә җитә. Кая барса да, туганнары, укучылары, хезмәттәшләре күп аның. Һәркайсы тормышының бер кисәгендә аның белән аралашкан, яшәгән, файдалы киңәшен алган. Бүген дә Борһановлар йортында ишек ябылып тормый: улы Фәрит һәм килене Гөлфинур әниләренә олы хөрмәт күрсәтеп, барлык туганнары өчен төп йорт булып тормышны дәвам итәләр. Гомере мәгънәле, хезмәте җимешле, дәрәҗәсе какшамас юбилярыбызның, шуның белән бәхетле дә ул.

**Люзия ВӘЛИУЛЛИНА,**

**Г.Кариев музее директоры.**



РОЗА БОРҺАНОВА МУЗЕЙДА УКУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН

# Фома матур гадәтләрен ташламый

**Узган атнада Фомада Авыл көне уңаеннан күңелләргә үтеп керерлек матур бәйрәм үтте.**

Бәйрәмне үткәрүдә авыл җирлеге башлыгы Рәшит Абдрахманов башлап йөрүче булды.

Мәдәният йорты каршында матур итеп сәхнә ясалган, ул шарлар белән бизәлгән, кунаклар өчен эскәмияләр куелган. Килүчеләрне хуш исле коймак, кайнап торган самавыр белән каршы алалар, бер якта нәниләр татлы мамык белән сыйлана.

Авыл көнен башлап җибәрү өчен иң беренче сүз Фома мәчетенең имамы Таһир хәзрәт Хәсәновка бирелде. Ул халыкны бәйрәм белән котлап, бу чараны үткәрергә ярдәм иткән авылдашларына рәхмәт белдерде һәм ил-көнгә тынычлык, иминлек теләп дога кылды.

Бәйрәмнең ниндиен генә үткәрсәң дә, ярдәмчеләрсез булмый. Авыл җирлеге башлыгы билгеләп үткәнчә, бу яктан фомалыларның мактанырлыгы бар. Барлык башлангычларда да иганәчеләр ярдәме күрсәтүче авылдашлары җитәрлек аларның. Мисал өчен, бу бәйрәм чыгымнарын Нәгыйм Абдулганиев, Фәнис Шәйхетдинов, Ислам Фәйзетдинов кебек шул авылда туып-үскән егетләр күтәрешкән.

– Бүгенге бәйрәм барыбызга да яхшы кәеф бирсен, чын күңелдән сезне бәйрәм белән котлыйм, барчагызга да иминлек, татулык һәм бәхет телим! Ә инде бәйрәмгә үзеннән өлеш керткән һәркемгә җирлек исеменнән олы рәхмәтемне белдерәм,– диде авыл җирлеге башлыгы Рәшит Абдрахманов.

Бәйрәм барышында авылның иң өлкән кешеләрен, Салих Нуретдинов, Минехаят Ситдыйкова, Нурия Вәлиуллина, лаеклы ялга чыгучы юбилярлар Мәдинә Зәйнуллина, Сәлим Сафиуллин һәм быел гаиләләрендә сабыйлары туганнарны истәлекле бүләкләр белән билгеләп үттеләр.

Халык чын күңелдән бәйрәм итте, бер якта балаларга ярышлар үткәрелсә, сәхнә каршында өлкәннәр кызыклы уеннарда көч сынаштылар.

Фома Авыл көнендә сыйныфташлар очрашуы үткәрү дә матур гадәткә әверелә бара, быел да 80нче елгы чыгарылыш укучылары шундый очрашу оештырганнар. Аларның Фома урта мәктәбен тәмамлауларына 35 ел булган.

**Гүзәлия МӘХМҮТОВА**

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»**

**С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон, 6-е в подарок***

**Деревенские окна по 2000 руб.**

**Откосы, подоконники, москитные сетки.**

**Работаем по всему Татарстану.**

**Рассрочка без % (предоставляет ИП Ахметов Ф.Ф.).**

***подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000.**

**ИП Ахметов Ф.Ф.**

**Требуются охранники с лицензией и без лицензии** для работы на промышленных объектах в городах РФ.

*График работы - две недели через две.*

Официальное трудоустройство. Бесплатное питание, проживание, доставка.

**З/п 850-900 руб. сутки для охранников без лицензии, 1000-1150 руб. сутки - с лицензией.**

**Т. 8 937 986 76 81.**

ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, И ДЕФЕКАТ 8-937-280-94-84.

Совет Ахметовского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан в соответствии со ст. 39.18 ЗК РФ от 25 октября 2001 года № 136 – ФЗ извещает о намерении предоставлении в аренду сроком на 49 лет земельного участка с кадастровым № 16:32:000000:224, с общей площадью 150,2325 га., из категория земель «Земли сельскохозяйственного назначения», разрешенный вид использования - для сельскохозяйственного производства, местоположение: РТ, Нурлатский муниципальный район, д. Ахметово, х-во СХК имени Хафизова.

Лица, заинтересованные в предоставлении земельного участка, в течении тридцати дней со дня опубликования извещения, в праве подавать заявления о намерении участвовать в аукционе на право заключения договора аренды земельного участка. Торги по продаже права на заключение договора аренды земельного участка будут проведены при наличии более одного заявления.

Заявки на участие в аукционе принимаются по установленной форме в письменном виде одновременно с полным комплектом документов требуемых для участия в аукционе с 8-00 до 17-00 в рабочие дни (перерыв с 12.00 до 13.00) по адресу: РТ, г. Нурлат, ул. Мугинова, д. 10, тел. (84345) 2-82-74, e-mail: Ahmet.Nur@tatar.ru .

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

**29 августа 2015 года**

1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология.
3. Терапия, кардиология, ревматология.
4. Сосудистая хирургия.
5. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании (цифровом аппарате) исследования сердца.

**5 сентября 2015 года**

1. Кардиология, ревматология.
2. Взрослая, подростковая гинекология.
3. Неврология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, ЭХО-энцефалографию, электроэнцефалографию, исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей (взрослым и детям).

**6 сентября 2015 года**

1. Гинекология, репродуктология. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Урология-андрология.
5. Отоларингология.
6. Врачи проведут исследования всех органов, плода на 1,2 и 3 триместрах (на полностью цифровом аппарате).

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».
Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г.
ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама

